**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

от 02.12.2019 1317-п

2012 елның 22 ноябрендәге 489-п номерлы Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны яңадан рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының норматив хокукый актларын федераль законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. 2012 елның 22 ноябрендәге 489-п номерлы Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы боерыгы (02.10.2013 ел, № 561-п, 17.10.2016 ел, № 1103-п, 05.06.2018 ел, № 553-п, 05.02.2019 ел № 89-п Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны яңадан рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына, аны яңа кушымта итеп бирелә торган редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

2. Җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлегенә (А.М.Чинарев) югарыда күрсәтелгән Регламент нигезендә эшләр башкаруны тәэмин итәргә.

3. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының хокукый тәэмин итү бүлегенә (М.М. Шәехов) әлеге боерыкны

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына дәүләт теркәвенә алуга җибәрергә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Т.Р.Гыйлаҗевка йөкләргә.

Министр А. В. Шадриков

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 22.11.2012 ел, № 489-п боерыгы белән расланган (02.12.2019 ел, № 1317-п боерыгы редакциясендә)

# Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны яңадан рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны яңадан рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге административ регламенты (алга таба - Регламент) Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны яңадан рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба - дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр: федераль законнарда башкача билгеләнмәгән булса, дәүләт хезмәте алуга гариза биргән эшмәкәрлек эшчәнлеге субъектлары, шул исәптән гади ширкәттә катнашучылар, чит ил гражданнары, юридик затлар.

1.3. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы (алга таба - Министрлык) тарафыннан күрсәтелә.

1.3.1. Министрлыкның урнашу урыны: Казан шәһәре, Павлюхин ур., 75.

Министрлыкның эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала, көн саен, дүшәмбе - пәнҗешәмбе 9.00дән 18.00гә кадәр, җомга 9.00дән 16.45кә кадәр, төшке аш 12.00дән 12.45кә кадәр.

Җәмәгать транспортында «Филармония» тукталышына кадәр барырга.

- № 2, 4, 5, 31, 37, 43, 47, 67, 74, 74а, 77 автобуслар;
- № 6, 8, 12 троллейбуслар.

Керү пропуск һәм (яки) шәхесне раслаучы документ буенча.

1.3.2. Министрлыкның Җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәсенең җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлегенең белешмә телефоны (алга таба - Бүлек): (843) 267-68-68.

1.3.3. Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба - Интернет челтәре) Министрлыкның рәсми сайты адресы: http://www.eco.tatarstan.ru.

1.3.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүмат түбәндәгечә алынырга мөмкин:

1) Министрлык биналарында мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен урнаштырылган дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст мәгълүматын үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аша.

2) «Интернет» челтәре аша:

Министрлыкның рәсми сайтында (http://www.eco.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталында (http://www.gosuslugi.ru/);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать иткәндә (шәхсән яисә телефон аша);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать иткәндә.

1.3.5. Министрлыкның урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайты, шулай ук электрон почта адресы турында мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында һәм Татарстан Республикасының Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында урнаштырыла.

Мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен Министрлык биналарындагы мәгълүмат стендларында урнаштырыла торган мәгълүмат әлеге Регламентның 1.1, 1.3.1, 2.1, 2.3 - 2.5, 2.7, 2.8, 2.9, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы (пунктчаларындагы) Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләрне үз эченә ала.

1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Салым кодексы (икенче өлеш), 2000 елның 5 августындагы 117-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба - РФ СК) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 07.08.2000, № 32, 3340 ст.);

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 21 февралендәге 2395-1 номерлы Россия Федерациясе Законы (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 10, 823 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба - «Җир асты байлыклары турында» РФ Законы);

«Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, № 43, 4190 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба - 127-ФЗ номерлы федераль закон);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 31, 4179 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба -

210-ФЗ номерлы федераль закон);

«Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 2012 елның 7 маендагы 601 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – 601 номерлы Президент Указы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2012, № 19, 2338 ст.);

«Җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү тәртибе турында нигезләмәне гамәлгә кертү тәртибе турында» 1992 елның 15 июлендәге 3314-1 номерлы Россия Федерациясе Югары Советы карары (Россия Федерациясе Халык депутатлары съезды һәм Россия Федерациясе Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 33, 1917 статья, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба - РФ Югары советы Нигезләмәсе);

«Җир асты байлыкларын геологик өйрәнүгә, рациональ файдалануга һәм саклауга дәүләт күзәтчелеге турындагы нигезләмәне раслау турында» 2005 елның 12 маендагы 293 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2005, № 20, 1885 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба-РФ Хөкүмәтенең 293 номерлы карары);

«Файдалануга бирелгән җир асты байлыклары кишәрлекләренең чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында нигезләмәне раслау турында» 2012 елның 3 маендагы 429 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 3 маендагы 429 номерлы карары белән расланган файдалануга бирелгән җир асты байлыклары кишәрлекләренең чикләрен билгеләү һәм үзгәртү турында нигезләмә (алга таба - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 3 маендагы 429 номерлы карары белән расланган Нигезләмә);

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 - 12, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба - «Җир асты байлыклары турында» ТР Законы);

«Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 6 июлендәге 325 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2005, № 28, 0654, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба - 325 номерлы ТР МК карары);

«Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү тәртибен раслау турында» 2009 елның 12 октябрендәге 715 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, яңадан рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү тәртибе («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2009, № 40, 1677 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба – № 715 ТР МК карары белән расланган Тәртип, Тәртип);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә һәм дәүләт функцияләрен башкарганда ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибе» 2012 елның 7 августындагы 674 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба - №674 ТР МК карары);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2010, № 46, 2144 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба - № 880 ТР МК карары);

«Татарстан Республикасы территориясендә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану тәртибен раслау турында» 2011 елның 4 ноябрендәге 917 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба - №917 ТР МК карары).

1.5. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия (алга таба - Лицензия) - дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органы тарафыннан бирелә торган, хуҗасының, алдан килешенгән шартларны үтәгән очракта, анда билгеләнгән максат нигезендә җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга хокукын таныклый торган документ;

лицензия килешүе (шартнамәсе) - дәүләт идарәсенең вәкаләтле органы һәм җир асты байлыкларыннан файдаланучы арасында җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары турында лицензиягә нигезләнгән килешү;

файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү - рациональ эшкәртү тирәнлегенә кадәр файдалы казылмаларны ачыклау күзлегеннән перспективасыз җир асты байлыклары кишәрлекләрендә нефть, газ һәм башка матдәләрне һәм материалларны саклау өчен, шул исәптән радиоактив, зарарлы һәм токсинлы матдәләрне һәм җитештерү калдыкларын күмү, агынты суларны (шул исәптән зарарлы һәм токсинлы матдәләр булган) агызу максатыннан куллану өчен җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү, торбаүткәргечләр һәм башка корылмалар төзү;

файдалы казылма - җир кабыгының матди җитештерү өлкәсендә нәтиҗәле кулланылырга мөмкин булган табигый минераль катламы;

запаслар - геологик разведка (тау, бораулау, сынау) эшләре нәтиҗәләре буенча турыдан-туры исәпкә алынган һәм исәпләнгән файдалы казылманың тупланма күләме һәм саны;

җир асты байлыкларыннан файдаланучы - федераль законнарда башкача билгеләнмәгән булса, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиясе булган эшмәкәрлек эшчәнлеге субъекты, шул исәптән гади ширкәттә катнашучылар, чит ил гражданнары, юридик затлар;

җир асты байлыкларыннан файдалану - җир асты байлыкларын геологик

өйрәнү, гомумтаралган файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгару, җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында, җир асты суларын табу, җирле әһәмияттәге җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү максатларында геологик өйрәнү;

җир асты суы - җир астындагы эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү яки сәнәгать объектларын яисә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларны технологик тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм чыгару күләме тәүлегенә 500 куб. метрдан артык булмаган су, - су алу проекты (эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү яки сәнәгать объектларын яисә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектларны технологик тәэмин итү максатларында кулланыла торган һәм чыгару күләме тәүлегенә 100 куб. метрдан артык булмаган җир асты суларыннан тыш);

җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге - гомумтаралган файдалы казылмалардан торган җир асты байлыклары кишәрлеге яисә файдалы казылмалар чыгаруга бәйле булмаган җирле һәм төбәк әһәмиятендәге җир асты корылмаларын төзү һәм эксплуатацияләү өчен файдаланыла торган җир асты байлыклары кишәрлеге, яисә эчәргә яраклы һәм хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү (алга таба - Эчәргә яраклы су белән тәэмин итү) яисә авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге сәнәгать объектларын технологик тәэмин итү максатларында кулланыла торган җир асты сулары булган җир асты байлыклары кишәрлеге;

техник хата - дәүләт хезмәте күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документларга кертелгән мәгълүматларның (дәүләт хезмәте нәтиҗәсе) аларны кертү өчен нигез булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата;

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең читтән торып эшләү урыны - «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләрен раслау турында» 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләре эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы муниципаль районының (шәһәр округының) шәһәр яисә авыл җирлегендә төзелгән Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы).

Әлеге Регламентта дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба - гариза) - ул 210-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать. Гаризаның тәкъдим ителә торган формасы әлеге Регламентка 1 нче кушымтада китерелгән.

2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына карата таләпнең аталышы | Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге | Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәтенең аталышы | Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны яңадан рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итүне гамәлгә ашыру | «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 16 ст. 6 абз.;<br>№3314-1РФ Югары Советы Нигезләмәсенең 1 п. 4 абз.,<br>«Җир асты байлыклары турында» ТР Законының 7 ст. |
| 2.2. Башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы | № 325 ТР МК карары 3.3.11 п. 14 абз. |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы | 1. Җир асты байлыкларыннан файдалануга теркәлгән лицензияне мөрәҗәгать итүчегә яки, тиешле ышанычнамәне күрсәткән очракта, аның законлы вәкиленә бирү.<br>2. Җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирүдән баш тарту һәм җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына лицензия бирүдән баш тарту турында дәлилләнгән хатны мөрәҗәгать итүчегә яки, тиешле ышанычнамәне күрсәткән очракта, аның законлы вәкиленә бирү (яки тапшыру | «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 10.1 ст. 6 п. , 11 , 17.1, 20, 21 ст.,<br>«Җир асты байлыклары турында» |

| | | |
|---|---|---|
| | турында хәбәре булган заказлы хатны җибәрү).<br>3. Җир асты байлыкларыннан файдаланyга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр булган лицензия кушымтасын мөрәҗәгать итүчегә яки, тиешле ышанычнамәне күрсәткән очракта, аның законлы вәкиленә бирү.<br>Лицензияне яңадан рәсмиләштергәндә җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары яңадан каралмый.<br>4. Җир асты байлыкларыннан файдаланyга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүдән баш тарту һәм җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүдән баш тарту турында дәлилләнгән хатны мөрәҗәгать итүчегә яки, тиешле ышанычнамәне күрсәткән очракта, аның законлы вәкиленә бирү (яки тапшыру турында хәбәре булган заказлы хатны җибәрү).<br>5. Җир асты байлыкларыннан файдаланyга яңадан рәсмиләштерелгән теркәлгән лицензияне мөрәҗәгать итүчегә яки, тиешле ышанычнамәне күрсәткән очракта, аның законлы вәкиленә бирү.<br>6. Җир асты байлыкларыннан файдаланyга лицензияне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту һәм җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукына лицензияне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында дәлилләнгән хатны мөрәҗәгать итүчегә яки, тиешле ышанычнамәне күрсәткән очракта, аның законлы вәкиленә бирү (яки тапшыру турында хәбәре булган заказлы хатны җибәрү).<br>7. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору турында карар һәм тапшыру турында хәбәре булган заказлы хат җибәрү яки шәхсән мөрәҗәгать итүчегә яки тиешле ышанычнамәне күрсәткән очракта, аның законлы вәкиленә бирү.<br>8. Җир асты байлыкларыннан файдалануны туктатып торудан баш тарту һәм җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануны туктатып торудан баш тарту турында дәлилләнгән хатны мөрәҗәгать итүчегә яки, тиешле ышанычнамәне күрсәткән очракта, аның законлы вәкиленә бирү (яки тапшыру турында хәбәре булган заказлы хатны җибәрү).<br>9. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турында карар һәм | ТР Законының 21 ст., РФ Югары советы Нигезләмәсе, № 715 ТР МК карары |

| | | |
|---|---|---|
| | тапшыру турында хәбәре булган заказлы хат җибәрү яки шәхсән мөрәҗәгать итүчегә яки тиешле ышанычнамәне күрсәткән очракта, аның законлы вәкиленә бирү.<br>10. Мөрәҗәгать итүчегә яки, тиешле ышанычнамәне күрсәткән очракта, аның законлы вәкиленә лицензия дубликатын бирү. | |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, туктатып тору мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору вакыты, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) вакыты | 1. Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм теркәлгән лицензияне бирү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү - гаризаны теркәгән вакыттан алып 40 эш көне, шул исәптән:<br>- мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирү яки мондый хокук бирүдән баш тарту турында карар кабул итү - гаризаны теркәгәннән соң 20 эш көне;<br>- лицензия һәм лицензиягә кушымталарны әзерләү һәм мөрәҗәгать итүчегә теркәлгән лицензияне тапшыру (җибәрү) – мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирү турында карар чыгарганнан соң 20 эш көне.<br>2. Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү һәм мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләрне үз эченә алган, теркәлгән кушымтаны бирү - гаризаны теркәгәннән соң 40 эш көне, шул исәптән:<br>- Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү яки Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүдән баш тарту турында карар кабул итү– гаризаны теркәгәннән соң 20 эш көне;<br>- Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүдән | № 715 ТР МК карарының 2.5 п., 2. 10 п. (№ 884 ТР МК карары редакциясендә);<br>№ 715 ТР МК карарының 2. 7 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | баш тарту турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү – баш тарту турында карар кабул ителгән көннән соң 3 эш көне;<br>- мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләрне үз эченә алган, теркәлгән кушымтаны бирү<br>- мөрәҗәгать итүчегә Татарстан Республикасында җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында карар чыгарганнан соң 20 эш көне.<br>3. Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияне яңадан рәсмиләштерү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү һәм мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалануга яңадан рәсмиләштерелгән лицензияне бирү - гаризаны теркәгәннән соң 40 эш көне, шул исәптән:<br>- Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияне яңадан рәсмиләштерү яки Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында карар кабул итү– гаризаны теркәгәннән соң 20 эш көне;<br>- Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү – баш тарту турында карар кабул ителгән көннән соң 3 эш көне;<br>- мөрәҗәгать итүчегә яңадан рәсмиләштерелгән һәм теркәлгән лицензияне һәм яңадан рәсмиләштерелгән лицензиягә җир асты байлыкларыннан файдалану шартлары турында лицензияле килешүне бирү – Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында карар чыгарылганнан соң 20 эш көне.<br>4. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү һәм мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору яки җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып торудан баш тарту турында теркәлгән карар җибәрү - гаризаны | |

| | | |
|---|---|---|
| | теркәгәннән соң 20 эш көне.<br>5. Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтү һәм мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турында теркәлгән карарны җибәрү һәм лицензияне дәүләт исәбеннән төшерү - гаризаны теркәгәннән соң 20 эш көне.<br>6. Лицензия дубликатын бирү - гаризаны теркәгәннән соң 20 эш көне.<br><br>Мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалануга теркәлгән лицензияне, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә кертелгән үзгәрешләр һәм өстәмәләрне үз эченә алган теркәлгән лицензия кушымтасын, җир асты байлыкларыннан файдалануга яңадан рәсмиләштерелгән лицензияне бирү турында карар кабул итү (20 эш көне) һәм тиешле документны әзерләү срогын (20 эш көне) үз эченә ала.<br>Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документ мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткән көнне бирелә.<br>Гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта аша яки электрон адреска), дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документны юллау дәүләт хезмәте нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган. | |
| 2.5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылырга тиешле, дәүләт хезмәтен күрсәтү һәм дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон актлары яки | 1. Гомумтаралган файдалы казылмаларны эзләү һәм чыгару максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү өлешендә дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүче түбәндәге документларны тапшыра:<br>а) дәүләт хезмәте күрсәтүгә гариза (әлеге Регламентка 1 нче кушымта);<br>б) гариза бирү вакытына файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең торышын чагылдыра торган һәм эшләрне башлауның планлаштырылган вакыты һәм җир асты байлыкларын һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча тәкъдим ителә торган чаралар турында мәгълүмат булган аңлатма язуы; | «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 23.2 ст., «Җир асты байлыклары турында» ТР Законының 35.2, 35.3, 35.4, 35.5, 35.8, 35.8.1, 35.8.2ст. (16.03.2018 ел, № 11- |

| | | |
|---|---|---|
| бүтән норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе | в) мөрәҗәгать итүченең гамәлгә кую документларының күчермәләре (мөрәҗәгать итүче юридик зат булса);<br>г) соңгы хисап датасына аны кабул итү турында салым органы тамгасы белән мөрәҗәгать итүченең бухгалтерия балансы күчермәсе;<br>д) гариза бирү датасына кадәр булган ай дәвамында мөрәҗәгать итүче счетлары буенча банк учреждениеләреннән акча хәрәкәте турында белешмәләр;<br>е) займ яки кредит шартнамәләре күчермәләре (булган очракта);<br>ж) подряд шартнамәләре күчермәләре (булган очракта);<br>з) мөрәҗәгать итүченең яисә җәлеп ителә торган подрядчыларның штат расписаниесе күчермәсе;<br>и) эшләр башкарачак квалификацияле белгечләрнең диплом күчермәләре,<br>к) кулланыла торган технологияләр турында тасвирламасы булган белешмәләр һәм мөрәҗәгать итүченеке яки җәлеп ителә торган подрядчыныкы булуы расланган бораулау һәм тау эшләрен уздыру өчен кирәкле техник чаралар исемлеге;<br>л) файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең топографик планы күчермәсе (өч нөсхәдә);<br>м) мөрәҗәгать итүче тарафыннан гомумтаралган файдалы казылмалар чыгару өчен файдаланыла торган эчке елга һәм катнаш ("елга-диңгез") йөзү судноларын "ГЛОНАСС" яки "ГЛОНАСС/GPS" спутник навигациясе аппаратурасы ярдәмендә "ГЛОНАСС+112" бердәм дәүләт мәгълүмат системасына тоташтыру өчен җиһазлар урнаштыру акты күчермәсе (мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән судноларда файдаланган очракта). | ТРЗ ТР Законы редакциясендә), Тәртипнең 2.1, 4.2, 4.3, 4.4. пунктчалары, Тәртипкә 2 нче кушымта, № 917 ТР МК карары. |
| | 2. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан җир асты суларын чыгару өчен, шулай ук җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында геологик өйрәнү өчен яки җир асты суларын эзләү һәм бәяләү, аларны чыгару максатларында геологик өйрәнү өчен, яки коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәтләрен һәм (яки) яшелчә бакчачылык ширкәтләрен хуҗалык-көнкүреш су белән тәэмин итү максатларында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирү | «Җир асты байлыклары турында» ТР Законының 35.8, 35.8.1, 35.8.2 ст. (16.03.2018 ел, № 11- |

| | | |
|---|---|---|
| | өлешендә дәүләт хезмәте алу өчен әлеге Регламентның 2.5 пунктындагы 1 пунктчаның «а», «б», «в», «г», «е» пунктчаларында каралган документлар кирәк, шулай ук:<br>а) файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә җир асты сулары запасларын раслау беркетмәсенең күчермәсе;<br>б) су алу скважинасы паспортының күчермәсе;<br>в) җир асты суларын чыгаруның билгеләнгән күләмен исәпләү һәм нигезләү;<br>г) мөрәҗәгать итүченең җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану шартлары буенча тәкъдимнәре, эшләрнең төрләрен, күләмнәрен, үткәрү срокларын, геологик өйрәнүнең, шул исәптән файдалы казылма запасларының артуы буенча көтелгән нәтиҗәләрен күрсәтеп, файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнү буенча тәкъдимнәре (җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән геологик өйрәнү өчен файдалану хокукы биргәндә);<br>д) файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеге турында түбәндәгеләрне үз эченә алган мәгълүмат:<br>- җир асты байлыклары кишәрлегенең геологик төзелеше турында мәгълүматлар, шул исәптән эксплуатацияләнә торган сулы горизонт турында мәгълүматлар;<br>- җир асты суларына ихтыяҗны һәм җир асты суларыннан максатчан файдалануны нигезләү;<br>- су әзерләү системасын куллану турында мәгълүматлар (булган очракта);<br>- су алу схемасы, җир асты байлыклары кишәрлегендә урнашкан скважиналарның географик координатлары;<br>- җир асты байлыклары кишәрлегендә урнашкан скважиналар конструкцияләре һәм билгеләнеше турында мәгълүматлар;<br>- су алу корылмасыннан файдалану режимының характеристикасы;<br>- җир асты суларының чыгарыла торган санын һәм сыйфатын тикшерү һәм исәпкә алу чаралары турында мәгълүматлар;<br>- җир асты байлыклары кишәрлегендә җир асты суларын билгеләнгән күләмдә чыгару мөмкинлеген нигезләү. | ТРЗ ТР Законы редакциясендә), Тәртипкә 7 нче кушымта |

| | | |
|---|---|---|
| | 3. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан лицензия килешүенең аерым пунктларын, шул исәптән чыгару күләмнәрен шактый үзгәртү сәбәпле, үтәү срокларын үзгәртү зарурлыгына бәйле рәвештә, лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү өлешендә дәүләт хезмәте алу өчен әлеге регламентның 2.5 пунктының 1 пунктчасындагы «а», «б» пунктчаларында каралган документлар кирәк, шулай ук:<br>- билгеләнгән таләпләр нигезендә рәсмиләштерелгән топографик план күчермәсе (үзгәртелә торган чикләрне чагылдырып һәм мәйданын күрсәтеп, сорала торган территориянең почмак нокталарының координатлары (географик һәм туры почмаклы) ведомосте белән)<br><br>Аңлатма язуында түбәндәгеләр булырга тиеш:<br>- шартларның үтәлешен раслаучы документларны һәм материалларны кушып биреп, гамәлдәге лицензиянең лицензия килешүе шартларын үтәү турында, лицензия алу датасыннан башлап, җир асты байлыкларыннан файдалану чорында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә үткәрелгән эшләр төрләре һәм күләмнәре турында мәгълүмат;<br>- үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү кирәклеген нигезләү өлешендә, шул исәптән лицензиянең гамәлдә булу вакытын үзгәртү буенча да, аңлатма;<br><br>җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеген зуарйткан очракта:<br>- тау һәм шартлату эшләрен куркынычсыз алып бару чикләрен исәпкә алып, файдалы казылма запасларын арттырудан башка җир асты байлыклары кишәрлеге чикләрен киңәйтүнең технологик ихтыяҗлары булу турында, тау эшләренең зыянлы йогынтысыннан саклау зоналары, тау токымнарын күчерү зоналары, табигать объектлары, биналар һәм корылмалар астында саклагыч целик контурлары, карьер һәм кисемнәр бортларын җимерү һәм җир өслегенә йогынты ясый торган башка факторлар турында мәгълүмат;<br>- җир асты байлыклары турында геологик һәм башка мәгълүмат ярдәмендә җир асты байлыклары кишәрлеге чикләреннән читтә җир асты байлыкларының түбән өлешендә булган, файдалы казылма запасларының дәүләт яки территориаль | 2012 елның 3 маендагы 429 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Нигезләмәнең 5 п., 7-16 п.,<br>«Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 23.2 ст., |

| | | |
|---|---|---|
| | балансына (алга таба - баланс) куелган файдалы казылмаларның әлеге файдалы казылма ятмасының бер өлеше булуы турында мәгълүматны раслау;<br>- җир асты байлыклары турындагы геологик һәм башка төрле мәгълүмат ярдәмендә җир асты байлыклары кишәрлеге чикләреннән читтә булган (җир асты байлыкларының түбән өлешеннән тыш), балансҡа куелган файдалы казылмаларның әлеге файдалы казылма ятмасының бер өлеше булуы турында мәгълүматны раслау;<br>- «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 23.2 статьясы нигезендә килештерелгән, дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәләрен алган техник проект турында мәгълүматлар;<br>- Татарстан Республикасының территориаль геологик мәгълүмат фондына тәкъдим ителгән геологик хисап турында мәгълүматлар;<br><br>җир асты байлыклары кишәрлеген киметкән очракта:<br>- җир асты байлыкларыннан файдаланучының җир асты байлыклары кишәрлегенең киметелгән өлешендә җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиядә күрсәтелгән һәм билгеләнгән тәртиптә дәүләт экспертизасы үткәрелгән файдалы казылмалар запаслары булмаса, җир асты байлыклары кишәрлегенең бер өлешеннән баш тартуы;<br>- җир асты байлыклары турындагы геологик һәм башка төрле мәгълүмат ярдәмендә җир асты байлыклары кишәрлегендә җир асты байлыкларын геологик өйрәнү һәм (яки) файдалы казылмаларны эзләү буенча үткәрелгән эшләрнең тиешле төре нәтиҗәләре буенча, җир асты байлыклары кишәрлегенең төшереп калдыру ниятләнгән өлешендә Татарстан Республикасының территориаль геологик фондына тәкъдим ителгән хисап белән расланган перспективалы геологик объектларның булмавы ачыклану турында мәгълүматларны раслау;<br>- әлеге кишәрлекнең җир асты байлыкларын геологик өйрәнү буенча эшләр башкарган җир асты байлыкларыннан файдаланучының үз (шул исәптән җәлеп ителгән) акчалары хисабына ачылган файдалы казылма ятмасын ачу фактын билгеләү турында мәгълүматлар; | |

| | | |
|---|---|---|
| | - балански куелган файдалы казылма запасларына дәүләт экспертизасы бәяләмәсе турында мәгълүматлар. | |
| | 4. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан лицензия бирелгән шартлардан шактый аерылып торган шартлар барлыкка килүгә бәйле рәвештә, лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү өлешендә дәүләт хезмәтен алу өчен әлеге Регламентның 2.5 пунктындагы 1 пунктчаның «а», «б» пунктчаларында каралган документлар кирәк.<br>Аңлатма язуында түбәндәгеләр булырга тиеш:<br>- шартларның үтәлешен раслаучы документлар һәм материалларны кушып биреп, гамәлдәге лицензиянең лицензия килешүе шартларын үтәү турында, лицензия алу датасыннан башлап, җир асты байлыкларыннан файдалану чорында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегендә үткәрелгән эшләр төрләре һәм күләмнәре турында мәгълүмат,<br>- кертелә торган үзгәрешләрне исәпкә алып, мөрәҗәгать итүченең җир асты байлыкларыннан файдалану шартларына кагылышлы тәкъдимнәре белән лицензия шартларына үзгәрешләр кертү зарурлыгын нигезләү;<br>- билгеләнгән таләпләр нигезендә рәсмиләштерелгән топографик план күчермәсе (үзгәртелә торган чикләрне чагылдырып һәм мәйданын күрсәтеп, сорала торган территориянең почмак нокталарының координатлары (географик һәм туры почмаклы) ведомосте белән) (лицензияле кишәрлекнең чикләренә кагылышлы үзгәрешләр булганда). | |
| | 5. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан лицензияне яңадан рәсмиләштерү өлешендә дәүләт хезмәте алу өчен лицензияне яңадан рәсмиләштерүгә дәгъва кылучы юридик зат түбәндәгеләрне үз эченә алган гаризаны бирә:<br>- мөрәҗәгать итүченең тулы рәсми атамасы;<br>- аның юридик адресы;<br>- яңадан рәсмиләштерелә торган лицензиянең төрен, номерын, датасын, җир асты байлыклары кишәрлегенең атамасын, җир асты байлыклары кишәрлегендәге | № 715 ТР МК карарының 4.2 п., «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе |

| | | |
|---|---|---|
| | эшләрнең максатчан билгеләнешен күрсәтеп, лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында үтенеч;<br>- «Җир асты байлыклары турында» Россия Федерациясе Законының 17.1 статьясында каралган лицензияне яңадан рәсмиләштерүне нигезләү;<br>- мөрәҗәгать итүченең яңадан рәсмиләштерелә торган лицензиядә каралган җир асты байлыкларыннан файдалану шартларын тулысынча үтәүне үз өстенә алырга ризалыгы.<br><br>Лицензияне яңадан рәсмиләштерүгә гаризага түбәндәге материаллар кушылып бирелергә тиеш:<br>- юридик затның билгеләнгән тәртиптә расланган гамәлгә кую документлары күчермәләре;<br>- лицензия хуҗасының, яңадан рәсмиләштерү нигезен күрсәтеп, лицензияне мөрәҗәгать итүчегә яңадан рәсмиләштерүгә рөхсәтен раслый торган документ (гариза бирү вакытына лицензия хуҗасы юридик зат статусын саклаган очракта);<br>- лицензияне яңадан рәсмиләштерүгә гариза мөрәҗәгать итүченең җитәкчесе тарафыннан имзаланмаган очракта, ышанычнамә;<br>- акционерлар реестрыннан өземтә (мөрәҗәгать итүчеләр - акционерлык җәмгыятьләре өчен);<br>- барлык кушымталары белән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга яңадан рәсмиләштерелә торган лицензиянең оригиналы;<br>- билгеләнгән таләпләр нигезендә рәсмиләштерелгән топографик план күчермәсе (үзгәртелә торган чикләрне чагылдырып һәм мәйданын күрсәтеп, сорала торган территориянең почмак нокталарының координатлары (географик һәм туры почмаклы) ведомосте белән) (лицензияле кишәрлекнең чикләренә кагылышлы үзгәрешләр булганда).<br><br>Җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы күчүнең конкрет нигезләвенә карап, мөрәҗәгать итүче өстәмә рәвештә түбәндәге документларны һәм | Законының 17.1 ст., |

| | | |
|---|---|---|
| | мәгълүматларны тапшырырга тиеш:<br>1) җир асты байлыкларыннан файдаланучы - юридик затны үзгәртеп кору - аның оештыру-хокукый формасын үзгәртү юлы белән яңадан оештырганда:<br>- лицензиягә дәгъва кылучы затның тиешле җир асты байлыклары кишәрлегенә хокук варислыгы билгеләнгән тәртиптә чагылдырылырга тиешле тапшыру акты (оригинал яки билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәсе);<br>2) Россия Федерациясе законнары нигезендә, юридик затны - җир асты байлыкларыннан файдаланучыны, аңа башка юридик затны кушу яисә аны башка юридик зат белән кушу юлы белән яңадан оештырганда яки җир асты байлыкларыннан файдаланучы - юридик затның, башка юридик затка кушылуы нәтиҗәсендә, эшчәнлеген туктатканда:<br>- лицензиягә дәгъва кылучы затның тиешле җир асты байлыклары кишәрлегенә хокук варислыгы билгеләнгән тәртиптә чагылдырылырга тиешле тапшыру акты (оригинал яки билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәсе);<br>- мөрәҗәгать итүченең җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга куела торган таләпләргә туры килүе турында, шулай ук җир асты байлыкларыннан файдаланугa бәйле эшләрне куркынычсыз башкару өчен кирәкле финанс һәм техник чаралар булуы һәм квалификацияле белгечләр булуы турында мәгълүматлар;<br>3) Россия Федерациясе законнары нигезендә, юридик затны - җир асты байлыкларыннан файдаланучы бүлү яисә аннан башка юридик затны аерып чыгару юлы белән яңадан оештырганда, әгәр яңа төзелгән юридик зат үз эшчәнлеген элеккеге җир асты байлыкларыннан файдаланучыга бирелгән лицензия нигезендә дәвам итәргә ниятләсә:<br>- лицензиягә дәгъва кылучы затның тиешле җир асты байлыклары кишәрлегенә хокук варислыгы чагылдырылырга тиешле бүлү балансы (оригинал яки билгеләнгән тәртиптә расланган күчермәсе);<br>- мөрәҗәгать итүченең җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга куела торган таләпләргә туры килүе турында, шулай ук җир асты байлыкларыннан файдаланугa бәйле эшләрне куркынычсыз башкару өчен кирәкле финанс һәм техник чаралар булуы һәм квалификацияле белгечләр булуы турында мәгълүматлар; | |

| | | |
|---|---|---|
| | 4) Әгәр юридик зат - җир асты байлыкларыннан файдаланучы җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензия нигезендә бирелгән җир асты байлыклары кишәрлегендә эшчәнлекне дәвам итү өчен төзелгән яңа юридик затны гамәлгә куючы булып тора икән:<br>- яңа юридик затның Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелүен һәм элекке юридик зат - җир асты байлыкларыннан файдаланучы өлешенең җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы күчкән вакытка мөрәҗәгать итүченең устав капиталының яртысыннан да ким булмаган өлешен тәшкил итүен раслаучы, тиешле тәртиптә таныкланган документлар күчермәләре;<br>- мөрәҗәгать итүчегә лицензиядә күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен, шул исәптән лицензия кишәрлеге чикләрендә төзекләндерү объектлары мөлкәте составыннан да, кирәкле мөлкәтнең тапшырылуы һәм җир асты байлыкларыннан файдалану белән бәйле эшчәнлек төрләрен (маркшейдер эшләрен башкаруга) тормышка ашыруга кирәкле лицензияләр булуы турында мәгълүматлар;<br>- мөрәҗәгать итүченең җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга куела торган таләпләргә туры килүе турында, шулай ук җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне куркынычсыз башкару өчен кирәкле финанс һәм техник чаралар булуы һәм квалификацияле белгечләр булуы турында мәгълүматлар;<br>5) җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы төп җәмгыять булган юридик зат - җир асты байлыкларыннан файдаланучыдан аның бүлендек җәмгыяте булган юридик зат - җир асты байлыкларыннан файдаланучыга бирелгән очракта, җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бүлендек җәмгыять булган юридик зат - җир асты байлыкларыннан файдаланучыдан аның төп җәмгыяте булган юридик зат - җир асты байлыкларыннан файдаланучыга бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүче төп һәм бүлендек җәмгыять статусын раслый торган документлар (Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә, төп һәм бүлендек җәмгыятьләрнең гамәлгә кую һәм теркәү документлары күчермәләре, акционерлар реестрыннан өземтә, төп җәмгыятьнең бүлендек җәмгыять кабул итә торган карарларны билгеләү мөмкинлеген раслаучы хуҗалык җәмгыятьләре арасында шартнамәләр яки башка | |

| | | |
|---|---|---|
| | документлар күчермәләре) тапшыра;<br>6) җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы төп җәмгыять булган юридик зат - җир асты байлыкларыннан файдаланучыдан аның бүлендек җәмгыяте булган юридик зат - җир асты байлыкларыннан файдаланучыга бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүче төп һәм бүлендек җәмгыять статусын раслый торган документлар (Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә, төп һәм бүлендек җәмгыятьләрнең гамәлгә кую һәм теркәү документлары күчермәләре, акционерлар реестрыннан өземтә, төп җәмгыятьнең бүлендек җәмгыять кабул итә торган карарларны билгеләү мөмкинлеген раслаучы хуҗалык җәмгыятьләре арасында шартнамәләр яки башка документлар күчермәләре) һәм лицензияне яңадан рәсмиләштерүгә төп җәмгыятьнең язма күрсәтмәсен тапшыра. Шулай ук мөрәҗәгать итүченең җир асты байлыкларыннан файдаланучыларга куела торган таләпләргә туры килүе, аның җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле эшләрне куркынычсыз башкару өчен кирәкле финанс һәм техник чаралары булуы, квалификацияле белгечләр булуы турында, шулай ук мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиядә күрсәтелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен, шул исәптән лицензия кишәрлеге чикләрендә төзекләндерү объектлары мөлкәте составыннан, кирәк булган мөлкәтнең, бирелүе турында мәгълүматлар тапшырылырга тиеш;<br>7) «Бөлгенлек (банкротлык) турында» Федераль законда каралган тәртиптә эшмәкәрлек эшчәнлеге субъекты тарафыннан банкрот предприятие (җир асты байлыкларыннан файдаланучы) мөлкәтен (мөлкәти комплексын) сатып алган очракта:<br>- мөлкәтне сатып алучының Россия Федерациясе законнары нигезендә төзелгән юридик зат булуы, җир асты байлыкларыннан файдаланучыга җир асты байлыклары турында Россия Федерациясе законнарының квалификация таләпләренә җавап бирүе турында мәгълүматлар;<br>- лицензия хуҗасына карата банкротлык процедурасы үткәрелүен раслаучы документлар, шул исәптән лицензия хуҗасының банкротлык процедурасын башлау турында суд карары күчермәсе; | |

| | | |
|---|---|---|
| | - лицензия хуҗасы булган предприятие-банкрот мөлкәтен (мөлкәти комплексын) сатып алуны һәм мөлкәтнең җир асты байлыкларының тиешле кишәрлегеннән файдалануга бәйле булуын раслаучы документлар (оригиналлар яки билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермә). | «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 21 ст. |
| | 6. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату һәм лицензияне дәүләт исәбеннән алу өлешендә дәүләт хезмәте алу өчен мөрәҗәгать итүчегә, билгеләнгән вакытка кадәр алты айдан да соңга калмыйча, түбәндәге документларны кушып гариза тапшырырга кирәк:<br>- гариза бирү вакытына файдалануга бирелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең торышын чагылдыручы һәм ятманы эксплуатацияләү эшләрен тәмамлаганда ятманы эшкәртүнең техник проектында каралган эшләрне башлауның планлаштырылган сроклары, җир асты байлыкларын һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча тәкъдим ителә торган чаралар турында мәгълүмат булган аңлатма язуы;<br>- лицензия килешүендә билгеләнгән барлык йөкләмәләрне һәм шартларны үтәү, әлеге йөкләмәләрнең һәм шартларның үтәлешен раслаучы документлар һәм материаллар, шулай ук предприятиене ябу һәм консервацияләү турында мәгълүмат. | «Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 26 ст. |
| | 7. Мөрәҗәгать итүче тарафыннан җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору өлешендә дәүләт хезмәтен алу өчен җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору чоры күрсәтелеп, түбәндәге документларны кушып, гариза тапшырырга кирәк:<br>- гариза биргән вакытка файдалануга бирелгән җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегенең торышын чагылдыручы, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору сәбәпләре һәм җир асты байлыкларын һәм әйләнә-тирә мохитне саклау буенча тәкъдим ителә торган чаралар күрсәтелгән аңлатма язуы;<br>- гариза бирү датасына, әлеге йөкләмәләрнең һәм шартларның үтәлешен раслаучы | |

| | | |
|---|---|---|
| | документлар һәм материаллар белән, лицензия килешүендә билгеләнгән йөкләмәләрне һәм шартларны үтәү турында мәгълүмат.<br><br>Документларның күчермәләре билгеләнгән тәртиптә (нотариаль яки мөрәҗәгать итүченең мөһере белән) таныкланырга яки оригиналларын күрсәтеп тапшырылырга тиеш.<br>Дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә ала.<br>Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Мөрәҗәгать итүче гариза һәм кушымта итеп бирелә торган документларны кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырырга (җибәрергә) мөмкин:<br>- шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышаныч кәгазе нигезендә эш итүче зат тарафыннан);<br>- почта аша. | |
| 2.6. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан аларны | Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында түбәндәгеләр алына:<br>- Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында өземтә яки Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсеннән (алга таба - ТР буенча ФСХИ) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрының язу кәгазе;<br>- Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан мөрәҗәгать итүче булган шәхси эшмәкәр турында өземтә яки Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсеннән Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрының язу кәгазе;<br>- салым түләүченең идентификация номеры күрсәтелеп, мөрәҗәгать итүчене салым органында исәпкә кую турындагы таныклык күчермәсе (ТР буенча ФСХИ);<br>- салым органнарыннан салымнар һәм җыемнар түләү буенча бурычлар булу яки булмау турында белешмә (ТР буенча ФСХИ);<br>- мөрәҗәгать итүченең һәм җәлеп ителгән подрядчыларның җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга бәйле эшчәнлек төрләренә лицензияләре | «Җир асты байлыклары турында» ТР Законының 35.2 ст. 3, 6 абз.;<br>Тәртипнең 4.5 п.;<br>№ 674 ТР МК карары. |

| | | |
|---|---|---|
| алу ысуллары, шул исәптән электрон рәвештә, аларны тапшыру тәртибе; карамагында әлеге документлар булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | күчермәләре;<br>- җир асты суларын эзләү һәм бәяләү максатларында файдалануга бирелә торган җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлеген геологик өйрәнү эшләрен башкаруга дәүләт контракты күчермәсе (дәүләт контракты нигезендә күрсәтелгән эшләр башкарылган очракта);<br>- Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең уңай тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәттән су объектының санитар кагыйдәләргә һәм су объектын куллануның халык сәламәтлеге өчен куркынычсызлык шартларына туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмә;<br>- дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасы түләвен раслый торган акча керү турында мәгълүмат (Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсе). | |
| | Мөрәҗәгать итүче тәкъдим итәргә хокуклы документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пункты белән билгеләнгән.<br>Мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>- дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яисә гамәлгә ашыру каралмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыру яисә гамәлләр башкару;<br>- Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган документларны һәм мәгълүматны, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш, шул исәптән дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткән өчен түләү кертүне раслаучы документлар һәм мәгълүматны тапшыру;<br>- 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясы 1 өлешендәге 4 пунктта каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканда булмавы | №210-ФЗ Федераль законның 7 ст. 6 өлеше<br>№210-ФЗ Федераль законның 7 ст. 1 өлеше 4. |

| | | |
|---|---|---|
| | һәм (яки) ялгышлыгы күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүматны бирү.<br><br>Мөрәҗәгать итүче әлеге пунктта күрсәтелгән мәгълүматларны үз эченә алган документларны, шул исәптән мөмкинлек булганда электрон рәвештә тапшырырга хокуклы.<br>Мөрәҗәгать итүченең әлеге пунктта күрсәтелгән документларны тапшырмавы дәүләт хезмәте күрсәтү өчен документларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тормый | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган комплектын бирү.<br>2. Билгеләнгән таләпләрне бозып гариза бирү.<br>3. Мөрәҗәгать итүче үзе турында күрәләтә ялган мәгълүматлар биргән<br>4. Мөрәҗәгать итүче эшне нәтиҗәле һәм куркынычсыз башкару өчен квалификацияле белгечләргә, кирәкле финанс һәм техник чараларга ия булуының яки ия булачагының дәлилләрен тәкъдим итми һәм тәкъдим итә алмый.<br>5. Әлеге мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирелгән очракта монополиягә каршы законнар таләпләре үтәлмәсә. | «Җир асты байлыклары турында» ТР Законының 35.9 ст.<br>«Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 14 ст.<br>«Җир асты байлыклары турында» РФ Законының 14 ст. 4 п. |
| 2.8. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яки аны күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр законда каралмаган.<br><br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр законда каралмаган | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасын яисә башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасы күләме Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә билгеләнгән:<br>- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирү - 7500 сум;<br>- җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне яңадан рәсмиләштерү - 750 сум;<br>- үзгәрешләр кертү (җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең гамәлдә булу срогы озайтылган очракта) - 750 сум.<br><br>Дәүләт хезмәте күрсәтүгә түләү мөрәҗәгать итүче тарафыннан акча күчерү юлы белән акчасыз исәп-хисап белән башкарыла.<br><br>Акча күчерү өчен реквизитлар:<br>Алучы: ТР БУЕНЧА РФ ФМ ФКИ (ТР ЭКОЛОГИЯ МИНИСТРЛЫГЫ)<br>ИНН 1659036508<br>КПП 165901001<br>Р/с 40101810800000010001<br>Россия Банкының ТР МБ ГРКЦ, Казан шәһәре<br>БИК 049205001<br>ОКТМО 92701000 (Казан)<br>КБК 70110807082011000110<br>Түләүнең билгеләнеше: җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирү / җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне яңадан рәсмиләштерү/ җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең гамәлдә булу вакытын озайту өчен дәүләт пошлинасы<br><br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча бирелгән документка министрлык һәм (яки) Министрлыкның вазыйфаи заты гаебе белән җибәрелгән хаталарны төзәтүгә юнәлдерелгән үзгәрешләр кертелгән очракта, мөрәҗәгать итүчедән түләү алынмый | РФ Салым кодексының 333.33 ст. 92 п. |

| | | |
|---|---|---|
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында мәгълүматлар | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәткән өчен түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре | Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгать биргәндә һәм мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта | Чират булган очракта, рөхсәт алу өчен кәгазьдә гариза бирү 15 минуттан да артмый.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта максималь көтү вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Дәүләт хезмәтләрен алучыларның аерым категорияләре өчен чиратлылык билгеләнмәгән | № 601 РФ Президенты Указы |

| | | |
|---|---|---|
| көтүнең максималь вакыты | | |
| 2.13. Дәүләт хезмәте һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать итүченең мөрәҗәгатен теркәү вакыты һәм тәртибе, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза кергәннән соң бер эш көне дәвамында.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә кергән мөрәҗәгать ял (бәйрәм) көненнән соң килүче икенче эш көнендә теркәлә | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатьләрне тутыру урыннарына, һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмат стендларына карата, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм | Дәүләт хезмәте янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар булган биналарда һәм бүлмәләрдә күрсәтелә.<br><br>Инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алу мөмкинлеге, шул исәптән объектларга тоткарлыксыз керү һәм алардан чыгу, шулай ук хезмәт күрсәтү урынына керү максатларында объект буенча мөстәкыйль рәвештә хәрәкәт итү мөмкинлеге тәэмин ителә.<br><br>Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла | |

| | | |
|---|---|---|
| мультимедиа мәгълүматны урнаштыру һәм рәсмиләштерүгә карата, шул исәптән, инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә, күрсәтелгән объектлардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итүгә карата таләпләр. | | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә мөрәҗәгать итүченең вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнешләре саны һәм аларның вакыт буенча | Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем өчен мөмкин булу күрсәткечләре:<br>– документларны кабул итү, бирү алып барыла торган биналарның җәмәгать транспортына якын зонада урнашуы;<br>– Министрлык бинасын һәм бүлмәләрен инвалидларның дәүләт хезмәте күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алу мөмкинлеген тудыручы чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин итү;<br>– белгечләрнең, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул ителә торган биналарның кирәкле санда булуы;<br>– мәгълүмат стендларында, Интернет челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;<br>– инвалидларга, биналарга аларның керә алу мөмкинлеген тәэмин итү белән | |

| | | |
|---|---|---|
| озынлыгы күрсәткече, дәүләт хезмәте күрсәтү турында, шул исәптән, мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне кулланып, мәгълүмат алу мөмкинлеге, дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән тулы күләмдә), мөрәҗәгать итүче сайлап алу буенча җирле үзидарә башкарма - боеру органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә (экстерриториаль принцип), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәкләрендә Федераль законның 15.1 статьясында каралган берничә дәүләт һәм | бәйле булмаган, башка затлар белән беррәттән аларга хезмәтне алуга комачаулаучы башка тоткарлыкларны узуда ярдәм күрсәтү.<br><br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре:<br>– документларны кабул итү һәм карау срокларын үтәү;<br>– дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогын үтәү;<br>– Министрлык белгечләре тарафыннан әлеге Регламентны бозуга нигезләнгән шикаятьләр булмау;<br>– мөрәҗәгать итүченең Министрлык белгечләре белән хезмәттәшлеге саны:<br>– дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны турыдан-туры тапшырганда - бердән артык түгел (консультацияләрдән башка);<br>– дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә - бердән дә артык түгел (консультацияләрдән башка).<br><br>Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүченең белгеч белән бер хезмәттәшлеге озынлыгы 15 минуттан артмый.<br><br>Мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең барышы турында мәгълүмат Министрлыкка телдән (шәхсән яисә телефон аша) мөрәҗәгать иткәндә яки язмача, шулай ук Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтында алынырга мөмкин<br><br>Күпфункцияле үзәктә (шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирү), КФҮнең читтән торып эшләү урыны аша дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый.<br><br>Экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы мөрәҗәгать буенча дәүләт хезмәте күрсәтү гамәлгә ашырылмый | |

| | | |
|---|---|---|
| (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында мөрәҗәгать аша дәүләт хезмәтен алу мөмкинлеге яисә андый мөмкинлек булмау | | |
| 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән экстетриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) исәпкә алучы таләпләр һәм электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләре | Консультация мөрәҗәгать итүче бүлеккә шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта, почта, Министрлык сайты http://www.eco.tatarstan.ru. базасында тормышка ашырылган Интернет-кабул итү бүлмәсе аша мөрәҗәгать иткәндә бирелергә мөмкин<br>Электрон формада дәүләт хезмәте күрсәтелми.<br>Электрон формада дәүләт хезмәте, шул исәптән «Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмати системасын кулланып та, күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән, аңа кушып бирелгән документлар, Министрлык сайты базасында тормышка ашырылган Интернет-кабул итү бүлмәсе аша электрон рәвештә бирелергә мөмкин: http://www.eco.tatarstan.ru.<br>Документларны электрон формада тапшыру өчен мәҗбүри шарт булып, аларны электрон имза белән 63-ФЗ номерлы федераль закон һәм 210-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзалау тора. | |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәү вакыты, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон рәвештә административ процедураларны (гамәлләрне) үтәү үзенчәлекләре

3.1. Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны яңадан рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән гаризаны язу өлешендә;

документлар кабул итү һәм гариза теркәү;

Министрлык карарын әзерләү һәм раслау:

мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирү турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турында;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору турында;

мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирүдән баш тарту турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүдән баш тарту турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең гамәлдә булуын туктатып торудан баш тарту турында;

түбәндәгеләрне әзерләү һәм мөрәҗәгать итүчегә тапшыру:

җирле әһәмияттәге җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә теркәлгән кушымта;

җир асты байлыкларыннан файдалануга яңадан рәсмиләштерелгән лицензия;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турында карар;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору турында карар;

лицензия дубликатын бирү;

техник хатаны төзәтү.

3.2. Мөрәҗәгать итүчегә консультация бирү

3.2.1. Мөрәҗәгать итүче Бүлеккә шәхсән, телефон һәм (яки) электрон почта аша дәүләт хезмәтләрен алу тәртибе турында консультация алу өчен мөрәҗәгать

итәргә хокуклы.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен тәкъдим ителә торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультацияләр бирә.

Кирәк булган очракта, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаны рәсмиләштерү өлешендә дә, ярдәм итә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура мөрәҗәгать итү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка мәсьәләләре буенча консультацияләр.

3.3. Документлар кабул итү һәм гариза теркәү.

3.3.1. Мөрәҗәгать итүче шәхсән үзе кәгазьдә йә почта аша, әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны кушып, Министрлыкка гариза тапшыра (җибәрә).

Дәүләт хезмәте күрсәтүне башлап җибәрә торган мөрәҗәгатьне бирү мөрәҗәгать итүчегә документларны рәсмиләштерү өлешендә ярдәм күрсәтүне таләп итми.

Гаризаны электрон рәвештә җибәргән очракта - соратылган документларның сканерланган күчермәләре, гаризаны заказлы хат белән җибәргәндә мөрәҗәгать итүче раслаган документлар теркәлә.

3.3.2. Министрлыкның документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризаны һәм аңа кушып бирелгән документларны кабул итү һәм теркәү;

гаризаны һәм әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмауга документларны тикшерү. Тикшерү Бүлек белгече катнашында башкарыла.

Мөрәҗәгать итүче шәхси мөрәҗәгать иткәндә, әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булган очракта, Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә документларны кабул итүдән һәм гаризаны теркәүдән баш тарту өчен нигезләрнең булуы турында хәбәр итә һәм, ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген аңлатып, документларны кире кайтара. Мөрәҗәгать итүче таләбе буенча баш тарту язмача рәсмиләштерелә.

Мөрәҗәгать итүче гариза һәм документларны почта аша җибәргәндә Бүлек белгече, баш тарту өчен ачыкланган нигезләрнең эчтәлеген язмача аңлатып, аңа почта аша кире кайтара.

Әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, гаризаны һәм кушып бирелгән документларны «Электрон хөкүмәт» Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документлар әйләнешенең бердәм ведомствоара системасында (алга таба - Электрон документ әйләнеше) терки.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: теркәлгән һәм министрга җибәрелгән гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар.

3.3.3. министр гаризаны карый һәм җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләре өчен җаваплы министр урынбасарына карауга җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министр урынбасарына карауга җибәрелгән гариза һәм аңа кушып бирелгән документлар.

3.3.4. Министр урынбасары гаризаны карый һәм аны Җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәсе башлыгына (алга таба - Идарә башлыгы) карауга җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Идарә башлыгына карауга җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.5. Идарә башлыгы гаризаны карый һәм Бүлек башлыгына карауга җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына карауга җибәрелгән гариза һәм документлар.

3.3.6. Бүлек җитәкчесе дәүләт хезмәте күрсәтү буенча җаваплы башкаручыны билгели.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар гариза теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә җибәрелгән гариза һәм аңа кушып бирелгән документлар.

3.4. Министрлык карарын әзерләү һәм раслау:

мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирү турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турында;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору турында;

лицензия дубликатын бирү турында;

мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирүдән баш тарту турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүдән баш тарту турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында;

лицензия дубликатын бирүдән баш тарту турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең гамәлдә булуын туктатып торудан баш тарту турында.

3.4.1. Бүлек белгече кергән гариза һәм аңа кушып бирелгән документлар нигезендә:

тапшырылган документларның әлеге Регламентның 2.5 пунктына туры килү-килмәвен анализлый;

мөрәҗәгать итүченең үз инициативасы белән тапшырылмаган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы тиешле дәүләт органнарыннан әлеге Регламентның 2.6 пунктында күрсәтелгән документларны бирү турында мөрәҗәгатьләрне формалаштыра һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша җибәрә:

- Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мөрәҗәгать итүче булган юридик зат турында мәгълүматлар яисә ТР буенча ФСХИдан Юридик затларның бердәм дәүләт реестрының язу кәгазен бирү турында;

- Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан мөрәҗәгать итүче булган шәхси эшмәкәр турында мәгълүмат бирү яки ТР буенча ФСХИдан Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрының язу кәгазе бирү турында;

- салым түләүченең идентификация номеры күрсәтелеп, мөрәҗәгать итүчене салым органында исәпкә кую турындагы таныклык күчермәсен бирү турында;

- мөрәҗәгать итүченең һәм җәлеп ителгән подрядчыларның җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга бәйле эшчәнлек төрләренә лицензияләре күчермәләрен бирү турында;

- су объектының санитар кагыйдәләргә һәм су объектын куллануның халык сәламәтлеге өчен куркынычсызлык шартларына туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмә күчермәсен бирү турында (Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең уңай тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт);

- дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасы түләвен раслый торган акча керү турында мәгълүмат бирү турында (Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсе);

- салым, җыемнар, пеня һәм законнарны бозган өчен штрафлар түләү буенча бурычлар булу (булмау) турында мәгълүматлар бирү хакында (ТР буенча ФСХИ, дәүләт күзәтчелегенең вәкаләтле органнары).

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар узган процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: анализланган документлар һәм ведомствоара хезмәттәшлек системасы кысаларында тиешле дәүләт органнарына җибәрелгән мөрәҗәгатьләр.

3.4.2. Мәгълүмат белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән, 3.4.1 пунктында күрсәтелгән мөрәҗәгать нигезендә, соратып алына торган документларны (мәгълүматларны) билгеләнгән срокта тапшыра.

Процедураларның нәтиҗәсе: алынган документлар (мәгълүматлар) яисә баш тарту турында Министрлыкка җибәрелгән хәбәрләр.

3.4.3. Бүлек белгече Бүлек башлыгына (ул югында - Бүлек башлыгы вазыйфаларын башкаручы затка ) түбәндәгеләрне әзерли һәм җибәрә:

әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булмаганда - Министрлык карары проектын:

мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирү турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору турында;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турында;

лицензия дубликатын бирү турында;

әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булганда - Министрлык карары проектын:

мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирүдән баш тарту турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүдән баш тарту турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында;

лицензия дубликатын бирүдән баш тарту турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең гамәлдә булуын туктатып торудан баш тарту турында.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар узган процедураны тәмамлаганнан соң 9 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгына килештерүгә юнәлтелгән Министрлык карары проекты.

3.4.4. Бүлек башлыгы Министрлык карары проектын килештерә һәм аны Министрлыкның каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге башлыгына (алга таба - каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге башлыгы) килештерүгә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.4.3 пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланганнан соң 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлек башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге башлыгына килештерүгә юнәлтелгән Министрлык карары проекты.

3.4.5. Каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге башлыгы (ул югында - каты файдалы казылмалар бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы) Министрлык карары проектын килештерә һәм аны Идарә башлыгына килештерүгә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.4.3 пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланганнан соң 1 эш көне дәвамында

гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге башлыгы белән килештерелгән һәм Идарә башлыгына килештерүгә юнәлдерелгән Министрлык карары проекты.

3.4.6. Идарә башлыгы (ул югында - Идарә башлыгы вазыйфаларын башкаручы) Министрлык карары проектын килештерә һәм аны Министрлыкның хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгына (алга таба - Хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы) килештерүгә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.4.3 пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланганнан соң 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Идарә башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгына килештерүгә юнәлдерелгән Министрлык карары проекты.

3.4.7. Хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы (ул югында - хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы) Министрлык карары проектын килештерә һәм аны министр урынбасарына (җир асты байлыкларыннан файдалану мәсьәләләре өчен җаваплы) (алга таба - министр урынбасары) килештерүгә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.4.3 пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланганнан соң 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкның хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм министр урынбасарына килештерүгә юнәлдерелгән Министрлык карары проекты.

3.4.8. Министр урынбасары (министр урынбасары вазыйфаларын башкаручы) Министрлык карары проектын килештерә һәм министрга имзаларга җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.4.3 пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланганнан соң 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министр урынбасары белән килештерелгән һәм министрга имзаларга юнәлдерелгән мөрәҗәгать итүче өчен Министрлык карары (хат, боерык) проекты.

3.4.9. Министр (ул югында - министр вазыйфаларын башкаручы зат) Министрлык карарын раслый:

мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирү турында;

җир асты байлыкларыннан файдалану лицензиясенә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турында;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору турында;

лицензия дубликатын бирү турында;

мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирүдән баш тарту турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүдән баш тарту турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында;

лицензия дубликатын бирүдән баш тарту турында;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең гамәлдә булуын туктатып торудан баш тарту турында.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура узган процедураны тәмамлаганнан соң 2 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: расланган Министрлык карары.

3.5. Түбәндәгеләрне әзерләү һәм мөрәҗәгать итүчегә тапшыру (җибәрү):

җир асты байлыкларыннан файдалануга теркәлгән лицензия;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә теркәлгән кушымта;

җир асты байлыкларыннан файдалануга яңадан рәсмиләштерелгән лицензия;

лицензия дубликаты;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турында карар;

җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору турында карар;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирүдән баш тарту турында хат;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында хат;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында хат;

лицензия дубликатын бирүдән баш тарту турында хат;

җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең гамәлдә булуын туктатып торудан баш тарту турында хат.

3.5.1. Министр тарафыннан расланган җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия бирүдән баш тарту турында, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүдән баш тарту турында, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне яңадан рәсмиләштерүдән баш тарту турында, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиянең гамәлдә булуын туктатып торудан баш тарту турында, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турында карар һәм җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору турындагы карар, Министрлыкның документларны үтәүне тикшерү бүлеге аша теркәлүдән соң, мөрәҗәгать итүчегә хат рәвешендә җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура узган процедураны тәмамлаганнан соң 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: теркәлгән һәм мөрәҗәгать итүче адресына җибәрелгән хат.

3.5.2. Министр тарафыннан Министрлык боерыгы рәвешендә расланган

мөрәҗәгать итүчегә җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирү турында, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензиягә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктату турында, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукын туктатып тору турында, лицензия дубликатын бирү турында карар, документларны үтәүне контрольдә тоту бүлегендә теркәлүдән соң, аны әзерләгән Бүлек белгеченә җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура әлеге Регламентның 3.5.1 пунктында билгеләнгән процедура тәмамланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә боерык рәвешендә җибәрелгән карар.

3.5.3. Бүлек белгече җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне, җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензия кушымтаны әзерләү өчен Министрлыкның җир асты байлыкларыннан файдалануны үстерү бүлегенә җир асты байлыкларыннан файдаланганда түләүләрнең икътисадый исәп-хисабын сорап мөрәҗәгать әзерли һәм җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура узган процедураны тәмамлаганнан соң 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җир асты байлыкларыннан файдаланганда түләүләрнең икътисадый исәп-хисабын сорап җибәрелгән мөрәҗәгать.

3.5.4. Министрлыкның җир асты байлыкларыннан файдалануны үстерү бүлеге белгече җир асты байлыкларыннан файдаланганда түләүләрнең икътисадый исәп-хисабын әзерли. Әзер икътисадый исәп-хисап рәсми язу рәвешендә Бүлеккә җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура әлеге Регламентның 3.5.3 пунктында күрсәтелгән процедура тәмамланганнан соң 2 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җир асты байлыкларыннан файдаланганда түләүләрнең әзерләнгән икътисадый исәп-хисабы.

3.5.5. Бүлек белгече икътисадый исәп-хисап алганнан соң түбәндәге проектны әзерли:

җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензия һәм лицензия килешүе;

җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензиягә кушымта;

мөрәҗәгать итүче адресына кушымтасы булган хат.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура узган процедураны тәмамлаганнан соң 12 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензиянең һәм лицензия килешүенең яки лицензиягә кушымтаның әзерләнгән проекты.

3.5.6. Бүлек белгече әзерләнгән лицензия һәм лицензия килешүе яки лицензия кушымтасының әзерләнгән проектын Бүлек башлыгына килештерүгә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.5.5 пунктында билгеләнгән процедура тәмамланганнан соң 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензиянең һәм лицензия килешүенең яки лицензиягә кушымтаның әзерләнгән һәм Бүлек башлыгына килештерүгә юнәлдерелгән проекты.

3.5.7. Бүлек башлыгы (ул югында - бүлек башлыгы вазыйфаларын башкаручы) лицензия һәм лицензия килешүе яки лицензиягә кушымта проектын килештерә һәм аны каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге башлыгына килештерүгә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.5.5 пунктында билгеләнгән процедура тәмамланганнан соң 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: бүлек башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге башлыгына килештерүгә юнәлдерелгән лицензия һәм лицензия килешүе яки лицензия кушымтасы проекты.

3.5.8. Каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге башлыгы (ул югында - файдалы каты казылмалар геологиясе бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы) лицензия проектын һәм лицензия килешүе яки лицензиягә кушымта проектын килештерә һәм аны Идарә башлыгына килештерүгә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.5.5 пунктында билгеләнгән процедура тәмамланганнан соң 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: каты файдалы казылмалар геологиясе бүлеге башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм Идарә башлыгына килештерүгә юнәлдерелгән лицензия һәм лицензия килешүе яки лицензия кушымтасы проекты.

3.5.9. Идарә башлыгы (ул югында - Идарә башлыгы вазыйфаларын башкаручы) лицензия һәм лицензия килешүе яки лицензиягә кушымта проектын килештерә һәм аны хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгына килештерүгә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.5.5 пунктында билгеләнгән процедура тәмамланганнан соң 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Идарә башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгына килештерүгә юнәлдерелгән лицензия һәм лицензия килешүе яки лицензия кушымтасы проекты.

3.5.10. Хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы (ул югында - хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы) лицензия һәм лицензия килешүе яки лицензиягә кушымта проектын килештерә һәм аны министр урынбасарына килештерүгә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.5.5 пунктында билгеләнгән процедура тәмамланганнан соң 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгы тарафыннан килештерелгән һәм министр урынбасарына килештерүгә юнәлдерелгән лицензия һәм лицензия килешүе яки лицензия кушымтасы проекты.

3.5.11. Министр урынбасары (ул югында - министр урынбасары вазыйфаларын башкаручы) лицензия һәм лицензия килешүе яки лицензия кушымтасы проектын килештерә һәм Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.5.5 пунктында билгеләнгән процедура тәмамланганнан соң 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министр урынбасары тарафыннан килештерелгән һәм мөрәҗәгать итүче тарафыннан кул куярга әзерләнгән лицензия һәм лицензия килешүе яки лицензия кушымтасы проекты.

3.5.12. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә әзерләнгән һәм килештерелгән лицензия һәм лицензия килешүе яки лицензиягә кушымта проекты һәм аңа Министрлыкта турыдан-туры шәхсән кул кую мөмкинлеге турында хәбәр итә, мөрәҗәгать итүченең Министрлыкта турыдан-туры кул кую мөмкинлеге булмаган очракта, Бүлек белгече лицензия һәм лицензия килешүе яки лицензиягә кушымта проектын почта аша (тапшыру турында хәбәре булган заказлы хат белән) имзаларга җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура, мөрәҗәгать итүче Министрлыкта шәхсән кул куйган очракта, алдагы процедура тәмамланганнан соң 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла, лицензия һәм лицензия килешүе яки лицензиягә кушымта проектын мөрәҗәгать итүче адресына почта аша рәсми хат итеп (тапшыру турында хәбәре булган заказлы хат) җибәргәндә, кул куюның дәвамлылыгы дәүләт хезмәте күрсәтү срогына керми.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүче тарафыннан имзаланган һәм министрга кул куюга юнәлдерелгән лицензия һәм лицензия килешүе яки лицензия кушымтасы проекты.

3.5.13. Министр (ул югында - министр вазыйфаларын башкаручы зат) түбәндәгеләргә кул куя:

җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензия һәм лицензия килешүе;

җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензиягә кушымта.

Министр тарафыннан имзаланган җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалануга лицензия һәм лицензия килешүе, лицензиягә кушымта мәгълүмати геологик ресурслар һәм геологик мохит мониторингы бүлегендә теркәлә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар әлеге Регламентның 3.5.12 пунктында билгеләнгән процедура тәмамланганнан соң 2 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: министр тарафыннан имзаланган һәм мәгълүмати геологик ресурслар һәм геологик мохит мониторингы бүлегендә теркәлгән лицензия һәм лицензия килешүе, лицензиягә кушымта.

3.5.14. Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә министр кул куйган лицензияне һәм лицензия килешүен, лицензиягә кушымтаны тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура узган процедураны тәмамлаганнан соң 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә тапшырылган министр кул

куйган һәм теркәлгән лицензия һәм лицензия килешүе, лицензиягә кушымта.

3.6. Лицензия дубликатын бирү.

Мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле), лицензия документларын югалткан яисә бозган очракта, Министрлыкка мөрәҗәгать итә.

3.6.1. Гаризаны кабул итү һәм теркәү

Лицензия дубликатын бирүгә гаризаны кабул итү һәм теркәү, әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булу-булмауга документларны тикшерү әлеге Регламентның 3.3 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.6.2. Хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәсен әзерләү.

Бүлек белгече әлеге Регламентның 2.7 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта:

әлеге Регламентның 3.4-3.5.2 пунктлары нигезендә процедураларны гамәлгә ашыра;

билгеләнгән формадагы лицензия дубликатын рәсмиләштерә һәм анда «Дубликат» мөһерен куя яки лицензия дубликатын бирүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, хат проектын әзерли;

әзерләнгән документлар проектларын министрга (аның вәкаләтле затына) кул кую өчен җибәрә.

3.6.1-3.6.2 пунктларында билгеләнгән процедуралар гариза кергәннән соң 19 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министрга кул куюга юнәлдерелгән документлар проектлары яки лицензия дубликатын бирүдән баш тарту турында хат проекты.

3.6.3. Министр (аның вәкаләтле заты) лицензия дубликатын бирү турындагы боерыкны раслый, лицензия документларының рәсмиләштерелгән дубликатын имзалый, аны Министрлык мөһере белән таныклый яки, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, лицензия дубликатын бирүдән баш тарту турында хатны имзалый. Кул куелган документлар Бүлек белгеченә җибәрелә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура узган процедураны тәмамлаганнан соң 1 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: имзаланган документлар.

3.6.5. Бүлек белгече:

гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып, мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында хәбәр итә, лицензия дубликатын бирү датасын һәм вакытын хәбәр итә;

лицензияләр реестрына лицензия дубликатын бирү турында мәгълүмат кертә;

мөрәҗәгать итүченең лицензия эшенә лицензия дубликаты күчермәсен терки.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар министр документларны имзалаган көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү.

3.6.6. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

Бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә, бирелгән лицензияләр журналында

лицензия дубликатын алу турында имза куйдырып, лицензия дубликатын бирә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура мөрәҗәгать итүче килгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: бирелгән лицензия дубликаты.

3.7. Техник хаталарны төзәтү.

3.7.1. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта техник хаталар (ялгыш язулар, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хаталар) ачыкланган очракта, мөрәҗәгать итүче Бүлеккә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү өчен гариза (әлеге Регламентка 2 нче кушымта);

мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак бирелгән, техник хата (ялгыш язулар, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хаталар) булган документ;

юридик көчкә ия булган, техник хата (ялгыш язулар, хәреф хаталары, грамматик яки арифметик хаталар) булуын дәлилләүче документлар.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән мәгълүматларда техник хатаны төзәтү турында гариза мөрәҗәгать итүче (аның вәкиле) тарафыннан шәхсән яисә почта аша яисә электрон почта аша тапшырыла.

3.7.2. Министрлыкның документлар үтәлешен контрольдә тоту бүлеге белгече техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итә, кушып бирелгән документлар белән гаризаны терки һәм аларны Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура гариза теркәлгән көндә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм теркәлгән, Бүлек белгеченә карауга җибәрелгән гариза.

3.7.3. Бүлек белгече документларны карый һәм хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатыннан әлеге Регламентның 3.5 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра, һәм мөрәҗәгать итүчедән (аның вәкиленнән) техник хата булган документның оригиналын алып, кул куйдырып, төзәтелгән документны мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) шәхсән тапшыра яки мөрәҗәгать итүче адресына почта аша (электрон почта аша) техник хата булган документның оригиналын күрсәткән очракта, документны алу мөмкинлеге турында хат җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнгән процедура техник хатаны ачыклаганнан яки теләсә кайсы мәнфәгатьле заттан җибәрелгән хата турында гаризаны алганнан соң 3 эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тоту тәртибе һәм рәвешләре

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедураларында билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелегенә агымдагы контроль дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Идарәләр (бүлекләр) башлыклары тарафыннан, әлеге Регламент нигезләмәләренең үтәлешен һәм башкарылуын тикшерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан гамәлгә ашырыла. Контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның вәкаләтләре Министрлыкның идарәләре (бүлекләре) турында нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.
4.3. Агымдагы контроль Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан әлеге Регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларның үтәлешен һәм башкарылуын тикшерү юлы белән гамәлгә ашырыла.
Агымдагы контроль даими нигездә гамәлгә ашырыла.
4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулы һәм сыйфатлы булуын контрольдә тоту дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләргә тикшерүләр үткәрүне, карауны, карарлар кабул итүне һәм җаваплар әзерләүне үз эченә ала.
Административ процедураларның үтәлешен тикшереп тоту рәвешләре булып түбәндәгеләргә тикшерү үткәрү тора:
– эш башкаруны алып бару;
– документларны карау нәтиҗәләренең законнар (әлеге Регламент) таләпләренә туры килүе;
– документларны кабул итү срокларын һәм тәртибен үтәү;
– дәүләт хезмәте күрсәткәндә нәтиҗәләр бирү срокларын һәм тәртибен үтәү.
Тикшерүләр планлы (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш (мөрәҗәгать итүченең конкрет мөрәҗәгате буенча) үткәрелә.
4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын планнан тыш тикшерүне үткәрү турында карар түбәндәге очракларда кабул ителә:
1) әлеге Регламент таләпләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларны элек ачыкланган бозуларны бетерүне тикшерү белән бәйле рәвештә;
2) Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының гамәлләре (гамәл кылмавы) аркасында аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләре бозылуга карата мөрәҗәгать итүчеләр шикаять белән мөрәҗәгать иткәндә.
4.6. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә мөрәҗәгать итүчеләр хокукларын бозу ачыкланган очракта, гаепле дип танылган дәүләт хезмәте өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җаваплылыкка тартыла.
4.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә карата гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан контроль дәүләт хезмәте күрсәткәндә Идарә (бүлек) эшчәнлегенең ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм дәүләт хезмәте күрсәтү вакытында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу юлы белән гамәлгә ашырыла.

5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), шулай ук аларның вазыйфаи затларына, дәүләт хезмәткәрләренә карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе.

5.1. Мөрәҗәгать итүчеләр дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Министрлык хезмәткәрләре, Министрлыкның вазыйфаи затлары, министрлыкның дәүләт граждан хезмәткәрләре карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр тәртиптә шикаятьне Министрлыкка бирергә хокуклы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү белән бәйле рәвештә министр карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

Мөрәҗәгать итүче шул исәптән түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатьне теркәү вакытын бозу;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын бозу;

3) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен, мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында тапшырылуы яки башкарылуы каралмаган документлар яисә мәгълүмат тапшыруны яисә гамәлләр башкаруны таләп итү;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен тапшырылуы Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында каралган документларны мөрәҗәгать итүчедән кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында баш тарту нигезләре каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту;

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган түләүне таләп итү;

7) Министрлыкның, Министрлык вазыйфаи затының дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы йә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозуы;

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда туктатып тору нигезләре каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору;

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән, 210-ФЗ номерлы федераль законның 7 статьясы 1 өлешендәге 4 пунктта каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканда булмавы һәм (яисә) ялгышлыгы күрсәтелмәгән документларны һәм мәгълүматны таләп итү.

5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазьдә яисә электрон рәвештә бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен, Министрлыкның рәсми сайтын (http://www.eco.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталын (http://uslugi.tatarstan.ru/), Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталын (http://www.gosuslugi.ru/) кулланып җибәрелергә, шулай ук мөрәҗәгать итүчене шәхсән кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьне карау вакыты - аны теркәгән көннән соң 15 эш көне дәвамында. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, әлеге органның вазыйфаи заты документлар кабул итүдән, мөрәҗәгать итүчедән, йә җибәрелгән басма хаталарны һәм башка хаталарны төзәтүдә баш тарткан очракта яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакыты бозылуга карата шикаять бирелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне дәвамында.

5.4. Шикаять түбәндәгеләрдән торырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең исеме;

2) мөрәҗәгать итүче физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), яшәү урыны турында белешмәләр йә мөрәҗәгать итүче юридик затның атамасы, урнашу урыны турында белешмәләр, шулай ук элемтә телефоны номеры, электрон почта адресы (булган очракта) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап юлланырга тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында белешмәләр;

4) мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм гамәле (гамәл кылмавы) белән килешмәвен нигезләүче дәлилләр.

5.5. Мөрәҗәгать итүчегә үзенең дәлилләрен раслаучы документлар (булган очракта) яки аларның күчермәләрен тапшырырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карау нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышлар һәм хаталарны төзәтү, мөрәҗәгать итүчегә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда алынуы каралмаган акчаларны кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Мөрәҗәгать итүчегә әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча язма рәвештә һәм мөрәҗәгать итүче теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карау нәтиҗәләре турында нигезләнгән җавап җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла торган

гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәтен алу максатларында мөрәҗәгать итүче кылырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, мөрәҗәгать итүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карау барышында яки аны карау нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карау вәкаләте бирелгән учреждение хезмәткәре булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны яңадан рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
1 нче кушымта

Форма
2009 елның 12 гыйнварындагы 715 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланды

Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрына
______________________________
(Ф. И. А.)

Аукцион үткәрмичә генә җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы алуга гариза

______________________________________________________________
җир асты байлыклары кишәрлегенең (ятмаларның) атамасы

1. Мөрәҗәгать итүче ______________________________________________
Юридик затның атамасы, җитәкченең Ф.И.А. вазыйфасы
______________________________________________________________

2. Дәүләт теркәве кодлары һәм реквизитлары:
______________________________________________________________
______________________________________________________________
ИНН, ОГРН, ОКПО, ОКОНХ, ОКОГУ, БИК, ОКАТО, ОКВЭД һ. б.
______________________________________________________________

3. Юридик адрес:
______________________________________________________________

Почта адресы:
______________________________________________________________

телефон: (код) ____________________, телефакс: (код)____________________
e-mail (булган очракта): ______________________________________

4. Мөрәҗәгать итүченең эшмәкәрлек максаты, ниятләнгән эшләр исемлеге:

______________________________________________________________________

Киң таралган файдалы казылмалар исемлеге нигезендә җир асты байлыкларыннан файдалану максатлары, файдалы казылма төре күрсәтелә

______________________________________________________________________,

эшләрне башкару вакыты:________________________________________________

______________________________________________________________________

5. Банк реквизитлары: ______________________________________________

счет номерлары, банк исемнәре

______________________________________________________________________

6. Кушып бирелә торган документлар исемлеге:

1) ______________________________

2) ______________________________

3) ______________________________

4) ______________________________

5) ______________________________

Җир асты байлыкларыннан файдалану төренә бәйле рәвештә, «Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә документлар

Предприятие җитәкчесе:

______________________________________________________________________

имза, Ф.И.А. М.У.

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны яңадан рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министрына
_______________________________
_____________________________________,
*(Җитәкче Ф.И.А., предприятие атамасы)*
лицензия серия___________№ ____________
җир асты байлыклары кишәрлеге ____________________________

Техник хатаны төзәтүгә гариза

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә ясалган хаталар турында хәбәр итәм
_____________________________________________________________________
*(хезмәтнең атамасы)*
Язылган: ___________________________________________________________
Дөрес мәгълүмат:
_____________________________________________________________________
Техник хатаны төзәтүегезне һәм дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документка тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.
Түбәндәге документларны кушып бирәм:
1.________________________________________________________
2.________________________________________________________
Техник хаталарны төзәтү турында гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта хәбәр итүегезне сорыйм:
- электрон документны түбәндәге адреска җибәрү юлы белән
E-mail: ____________________________________________;
- түбәндәге адрес буенча почта аша хатта кәгазьдә расланган күчермә рәвешендә:
____________________________________________________________________

______________________________________________(______________________)

*(дата)* *(имза)* *(Ф.И.А.)*

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны яңадан рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмә)

Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга лицензияләрне рәсмиләштерү, дәүләт теркәвенә алу һәм бирү, аларга үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү, шулай ук аларны яңадан рәсмиләштерү һәм Татарстан Республикасында җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалану хокукын вакытыннан алда туктату һәм туктатып тору турында карарлар кабул итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү һәм аны күрсәткәндә контрольне гамәлгә ашыру өчен җаваплы вазыйфаи затларның реквизитлары

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы

| Вазыйфа, ФИА | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры Шадриков Александр Валерьевич | 267-68-01 | eco@tatar.ru |
| Министр урынбасары Гыйлаҗев Тимур Рөстәм улы | 267-68-26 | Timur.Gilyazov@tatar.ru |
| Җир асты байлыкларыннан файдалану мөнәсәбәтләрен җайга салу идарәсе башлыгы Вахитов Самат Таһир улы | 267-68-60 | Samat.Vahitov@tatar.ru |
| Җир асты байлыкларыннан файдалануны лицензияләү бүлеге башлыгы Чинарев Андрей Александрович | 267-68-68 | Aleksey.Chinarev@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының дәүләт хезмәте күрсәткәндә контрольне гамәлгә ашыру өчен җаваплы вазыйфаи затлары реквизитлары

| Вазыйфа, Ф. И. А. | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү бүлеге | 264-77-46 | pisma@tatar.ru |